**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2021 ел, 5 июль №32

**Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советына төзекләндерү өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге вәкаләтләрне тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

җирлек территориясендә җир эшләрен җитештерүгә рөхсәт бирү;

җирлек территориясендә тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлеге башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлеге Советының 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Тутай авыл җирлеге**
**Башлыгы**
**Тутай авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Н.М. Насретдинова**